| «Рассмотрено» | «Согласовано» | «Утверждаю» |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО ГЦ | Заместитель директора по УР | Директор МБОУ |
| _______ С.Г.Сафиуллина | МБОУ «Большеелгинская СОШ» | «Большеелгинская СОШ» |
| Протокол №1 | _______ Э.Р.Валеева | _______ Г. М. Миннигалеева |
| от «_29_» августа 2025 г. | «_29_» августа 2025 г.; | Приказ № 71 о/д |
| | | от «_29_» августа 2025 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
## курса внеурочной деятельности
## “Театр яктылыкка, нурга илтә”
## для 8 класса МБОУ «Большеелгинская средняя общеобразовательная школа»
## на 2025-2026 учебный год

Составитель:
учитель татарского языка и литературы
Мубаракшина А.А.

**Рассмотрено на заседании педагогического совета**

**протокол №1 от « 29 » августа 2025 г.**

2025

# Пояснительная записка

Рабочая программа курса внеурочной деятельности составлена на основе следующих нормативно-правовых документов:

1. Закона Российской Федерации от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (далее - Федеральный закон № 273-ФЗ);
2. Федеральный государственный образовательный стандарт среднего общего образования (Приказ Минпросвещения России №413 от 17.05.2012, ред.№8 от 27.12.2023);
3. Федеральная образовательная программа основного общего образования (Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 18 мая 2023 года №370 от 18.05.2023);
4. План внеурочной деятельности МБОУ «Большеелгинская средняя общеобразовательная школа» Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан на 2025-2026 учебный год, утвержденный приказом № 70 о/д от 29.08.2025 года;
5. Годовой календарный учебный график МБОУ «Большеелгинская средняя общеобразовательная школа» Рыбно-Слободского муниципального района Республики Татарстан на 2025-2026 учебный год, утвержденный приказом № 71 о/д от 29.08.2025 года.
6. Устав МБОУ «Большеелгинская СОШ»; Положение о рабочей программе МБОУ «Большеелгинская СОШ»

**“Театр- яктылыкка, нурга илтә” дәрестән тыш эшчәнлекнең эш программасы**

**Аңлатма язуы**

Театр – сәнгатьнең бер төре. Ул үз эченә әдәбият, музыка, бию, сынлы сәнгатьне берләштерә. Сәнгатьле сөйләм формалаштырганда балага белем бирү шартлары гына түгел, ә аларны эшкәртергә һәм үзләренең карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә. Моның өчен иң әйбәт чара булып театральлештергән шөгыльләр тора. Театр иң демократик, яшь үзенчәлекләренә туры килерлек сәнгать төре. Ул педагогик һәм психологик актуаль проблемаларны хәл итәргә булыша. Алар әхлак тәрбиясе бирергә, коммуникатив шәхес формалаштырыга, күзаллау, фантазия, инициатива, фикер йөртүгә, туган телне яратырга ярдәм итә. Театр сәнгате аша балалар образлар, тавыш, буяу аркылы әйләнә-тирә белән танышалар, зәвык һәм әхлак тәрбиясе алалар. Тормышның көзгесе булган әлеге сәнгать укучыларны яңа хисләр, белемнәр, күнекмәләр белән баетырга, матур әдәбиятка кызыксыну уятырга, сүз байлыгы, сөйләм телен үстерергә ярдәм итә.

Бүгенге көндә үсеп килүче яшь буынны халкыбызның традицияләре үрнәгендә тәрбияләү- мөһим бурычларның берсе. Балага милли гореф-гадәтләр, милли традицияләр никадәр иртәрәк бирелсә, ул шәхес буларак шулкадәр көчле, телен, илен, милләтен сөя белүче булып үсәчәк.Үз телен, милләтен, мәдәниятен белеп, аңа хөрмәт белән карый белүче генә башка милләт вәкилләрен, аларның гореф-гадәтләрен ихтирам итә белә. Туган телне, милли мәдәниятне өйрәнеп һәм янәшә яшәүче башка халыкларның да теленә, мәдәниятенә, милли традицияләренә тирән ихтирам белән карый белүче балалар безнең мәгариф һәм милли мәдәниятне үстерүнең нигез ташын тәшкил итәргә тиеш.

“Театр – яктылыкка, нурга илтә” түгәрәге укучыларның сәләтләрен ачарга, уй- хыялларын үстерергә мөмкинлек бирә, матурлыкны күрә белергә өйрәтә, иҗади эшчәнлекне баета.

Адәм баласы, укучылар хисләр дәрьясында яши, әйләнә-тирәдә булган вакыйгаларны йөрәге аша үткәрә. Бүгенге укучыларның күңел түрләренә үтеп кереп, аны уйланырга, нәтиҗә чыгарырга, сабак алырга ярдәм итүче иң кулай ысулларның берсе театр сәнгате дип уйлыйм. Җәмгыятьтә үз урыннарын табу, тормышның тайгак юлларында абынмау, үз кыйблаларын саклап калу, иң мөһиме камил шәхес тәрбияләү бурычы өстендә эшләү күз алдында тотыла.

Электив курс дәресләре төрле формада үткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

Курс югары сыйныф IX-XI укучылары өчен төзелә. Актер, журналист һөнәрен үзләштерергә теләүчеләр өчен курсның әһәмияте мөһим.

**Максаты :**

1. Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга һәм образларны иҗат итәргә өйрәтү.
2. Татар театры тарихы, анын беренче карлыгачлары, беренчел адымнары белән кызыксыну хисләре уяту.
3. Татар театры сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, әхлак сыйфатлары формалаштыру, киләчәк тормышка әзерләү.
4. Сәнгатьле уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.

**Бурычлары :**

1. Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.
2. Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.
3. Театрның үткән юлын, аның беренче яралгыларын аңлауларына ирешү.
4. Драма жанрының төрләрен аера алуларын булдыру.
5. Классик әсәрләр сәхнәләштерү.
6. Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.
7. Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

**Программаның актуальлеге.**

Федераль дәүләт стандартларын гамәлгә ашыру шартларында мәгариф алдына һәр яктан камил, мөстәкыйль һәм иҗади шәхес тәрбияләү максаты куелды. Укучыларга дәресләрдән тыш өстәмә белем бирү дә – заман куйган таләпләрнең берсе. Авторлык программасы әлеге максатка ярашлы шәхесне үстерүгә юнәлдерелгән технология нигезендә эшләнде.

**Тематик планлаштыру**

| | Бүлек исеме |
|---|---|
| 1 | Кереш дәрес |
| 2 | Татар театры тарихы |
| 3 | Татар театрының бүгенгесе, киләчәге |
| 4 | Теория |
| 5 | Сәхнә серләре |
| 6 | «Беренче театр» әсәре |
| 7 | Экскурсия |
| 8 | Шәриф Хөсәенов “Әни килде” әсәрен сәхнәләштерү |
| 9 | Йомгаклау |

**Курсның эчтәлеге**

**Календарь-тематик планлаштыру**

| № | Дәреснең темасы | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | Искәрмә. |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. Сәнгать төре буларак театр. Татар театр сәнгатенең роле, әһәмияте. | 1 | 3.09 | |
| 2 | Театр сәнгатенең төп үзенчәлеге. | 1 | 10.09 | |
| Татар театры тарихы | | | | |
| 3 | Татар театры тарихы, аның беренче адымнары, үткән юлы. | 1 | 17.09 | |
| 4 | Татар театрының ачык рәвештә куелу тарихы | 1 | 24.09 | |
| 5 | Беренче дрматурглар иҗаты. Габдрахман Ильяси,Фатих Халиди, Гаяз Исхакый, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин. | 1 | 1.10 | |
| 6 | Театрның беренче карлыгачлары. | 1 | 8.10 | |
| 7 | «Сәяр» труппасы, аның иҗаты, йолдызлары | 1 | 15.10 | |
| 8 | Татар Дәүләт театры, аның беренче иҗат труппасы. | 1 | 22.10 | |
| Татар театрының бүгенгесе, киләчәге | | | | |
| 9 | Татар театрының бүгенгесе, киләчәге. | 1 | 12.11 | |
| 10 | Г.Камал һәм К.Тинчурин театры эшчәнлеге. | 1 | 19.11 | |
| 11 | М.Җәлил опера һәм балет театры, , Яшь тамашачылар театрлары тарихы, эшчәнлеге. | 1 | 26.11 | |
| 12 | “Әкият” курчак театры | | 3.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | Минзәлә һәм Әлмәт театрлары. | 1 | 10.12 | |
| 14 | Якташ актерларыбыз иҗаты. | 1 | 17.12 | |
| 15 | Бүгенге драматурглар, аларның иҗат алымнары. | 1 | 24.12 | |
| 16 | Театр сәнгатенә өлеш керткән актерлар, актрисалар, режисерлар. | | 14.01 | |
| 17 | Драма жанрлары: трагедия, драма, мелодрама | 1 | 21.01 | |
| 18 | Комедия, водевиль. | 1 | 28.01 | |
| 19 | Сюжет. Композиция. Төенләнеш. Чишелеш. | 1 | 4.02 | |
| 20 | Конфликт. Ремарка. | 1 | 11.02 | |
| Сәхнә серләре | | | | |
| 21 | Сөйләм үзенчәлекләре. | 1 | 18.02 | |
| 22 | Сәнгатьле сөйләм үстерү | 1 | 25.02 | |
| 23 | Интонация. Басым. | 1 | 4.03 | |
| 24 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. | 1 | 11.03 | |
| 25 | Мимика бирү юллары. | 1 | 18.03 | |
| 26 | Хисләрне җиткерү алымнары. | 1 | 25.03 | |
| Классик спектакльләр | | | | |
| 27 | Г.Камал иҗаты белән танышу. “Беренче театр” әсәрен карау. | 1 | 8.04 | |
| 28 | Г.Исхакыйның “Зөләйха” спектаклендә образларның үзенчәлекләре. | 1 | 15.04 | |
| 29 | К.Тинчуринның “Зәңгәр шәл” спектаклендә образларның бер-берсе белән бәйләнеше. | 1 | 22.04 | |
| 30 | Г.Камал театрына экскурсия(онлайн) | 1 | 29.04 | |
| 31 | Шәриф Хөсәенов иҗаты белән танышу. “Әни килде” спектаклен карау | 1 | 6.05 | |
| 32 | Аяз Гыйләҗевның “Өч аршин җир”, “Көттереп искән җил” спектакльләренең тәрбияви әһәмияте. | 1 | 13.05 | |
| 33 | Туфан Миңнуллин язган спектакльләрнең актуальлеге. Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау, йомгаклау. | 1 | 20.05 | |

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш :**

1. Театр сәнгате, аның төп үзенчәлеге.
2. Татар театр сәнгате, аның тәүге адымнары, формалашу чоры, үткән юлы.
3. Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачлары (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).
4. Драма жанрлары.
5. Классик драма әсәрләре, классик драматурглар иҗаты.
6. Актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү.
7. Режиссер күрсәтмәләрен аңлый, үти белү.
8. Мәдәниятне аңлый белүче, иҗади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу.

**Укучы эшли, башкара белергә тиеш :**

1. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера.
2. Татар театры тарихы, үткән юлы белән таныш.

3. Сәнгатьле сөйли, образга керә.
4. Актерлык талантына ия.
5. Иҗади һәм мөстәкыйль, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.
6. Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне аңлый.
7. Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксына.

**Әдәбият исемлеге.**

**Укытучы өчен:**

1 Хәнүз Мәхмүтов., Илтани Илялова, Бәян Гыйззәт.Октябрьгә кадәрге татар театры..- Казан, 1988.
2 Б.Гыйззәт, Х.Мәхмүтов, А.Әхмәдуллин, И.Илялова. Татар совет театры.- Казан, 1975.
3 А.Әхмәдуллин. Сәхнә һәм тормыш.- Казан, 1976.
4. Р.Җиһаншина. Күңелем түреннән.
5. Төрле журналлар, альбомнар, белешмәләр, рәсем-фотолар, артист язмалары.
6. Әдәбият дәреслекләре.
7. Сәхнә әсәрләре.

**Укучылар өчен әдәбият:**

8 Мәктәп сәхнәсе. 1-2 кисәк.
9 Пионер сәхнәсе. 6-8кисәк.
10 Ш.Галиев. Күңелле сәхнә.- Казан, 1971.
12 Мәзәкләр җыентыгы.
13 Классик драматурглар иҗаты үрнәкләре.
14 И. Нуруллин. Драматургиядә жанр формалары.